ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**МЕНДЕЛЕЕВСК ШӘҺӘР СОВЕТЫ**

423650, Менделееев шәһәре, Фомин урамы
Тел. 2-10-69, 2-16-95, факс 2-12-91

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**МЕНДЕЛЕЕВСКИЙ ГОРОДСКОЙ СОВЕТ**
423650, г. Менделеевск, улица Фомина
Тел. 2-10-69, 2-16-95, факс 2-12-91

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

№ 59 07 08.2018

19.12.2017 елгы 53-нче номерлы «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Менделеевск шәһәре территорияләрен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» Менделеевск муниципаль районы Менделеевски шәһәр Советы карарына үзгәрешләр кертү турында

06.10.2003 елгы № 131 - ФЗ номерлы "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " федераль законына, Татарстан Республикасының Менделеевск муниципаль районы «Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә, 31.05.2018 елгы №23/1-07-2018 Кама транспорт прокуратурасы һәм 16.01.2018 елгы №02-06-2018 Казан районара табигать саклау прокуратурасы күрсәтмәләрен карап, Менделеевск муниципаль районы Менделеевск шәһәре Советы КАРАР кылды:

1. 19.12.2017 елгы 53-нче номерлы «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Менделеевск шәһәре территорияләрен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» Менделеевск муниципаль районы Менделеевск шәһәр Советы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:
   1.1 Кагыйдәнең 19-нчы пунктын төшереп калдырырга.
   1.2 Кагыйдәнең 3.9 пунктының 15-нче пунктчасын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә: “Автовокзалларда, базарларда, паркларда, бакчаларда, ял итү зоналарында, мәгариф, сәламәтлек саклау һәм башка халык күп җыела торган урыннарда, урамнарда, шул исәптән шәхси йортлар төзелгән урамнарда, торак йортларның подъездлары янында, шәһәр пассажир транспорты тукталышларында, сәүдә объектлары каршында чүп савытлары куелырга тиеш. Чүп савытлары шәхси торак йортлар хуҗалары, объект арендаторлары тарафыннан куела. Урналар түбәндәге тәртиптә куела: бер-берсеннән 40 метр аша - төп магистраль

урамнарында, базарларда һәм башка халык күп җыела торган урыннарда; бер-берсеннән 100 метр аша – башка урамнарда, паркларда, бакчаларда һәмбашка территорияләрдә, пассажир транспорты тукталышларында, сәүдә объектлары каршында икедән ким булмаска тиеш".

1.3 Кагыйдәнең 5.4 пунктының 7,8,11-нче пунктчаларында "тимер юл" сүзен төшереп калдырырга. Кагыйдәнең 6-нчы разделын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә: "Менделеевск муниципаль районы Менделеевск шәһәрендә йорт хайваннарын һәм кошларын тоту". 6.1 пункты – "Бөтен эре мөгезле терлек, сарык, ат, кәҗәләр бары тик загоннар эчендә, йорт яны территорияләрендә яисә көтүче күзәтелегендә тотылырга тиеш. Йорт хайваннарын тоту аркасында территориянең, күп катлы йортларның этаж арасындагы мәйданчыкларның санитар торышын бозган өчен җаваплылык йорт хайваннарының хуҗаларына йөкләнә".

2. Бу карарны Менделеевск муниципаль районы рәсми сайтының http://.mendeleevsk.tatarstan.ru «Норматив документлар» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырырга.
3. Бу карар официаль бастырылып чыгарылганнан соң үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне законлылыкны үтәү, хокук тәртибе, кеше хокуклары һәм депутат этикасы буенча даими комитетына тапшырырга.

Менделеевск муниципаль районы
Менделеевск шәһәре советы рәисе В.С.Чершинцев